ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУСЛЮМОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

06.12.2022 М ө с л и м № 719

**2023 елга халыкка күрсәтелә торган торак-коммуналь хезмәтләргә тарифлар турында**

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне карап тоту кагыйдәләрен һәм күпфатирлы йортта идарә итү, аны карап тоту һәм ремонтлау эшләрен сыйфатсыз һәм (яки) тәнәфесләр белән билгеләнгән вакыттан артып киткән дәвамлылыкта башкарган очракта торак урынны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен үзгәртү кагыйдәләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 13 августындагы 491 номерлы карары, «2020 елга Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә коммуналь хезмәтләр өчен түләүнең иң чик (максималь) индекслары турында» 2021 елның 15 декабрендәге ПУ-958 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указы, «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт өчен кертемнең минималь күләмен билгеләү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 29 июнендәге 450 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 03 декабрендәге 1097 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2023 елның 1 гыйнварыннан 2023 елның 31 декабренә кадәр түбәндәгеләрне расларга һәм гамәлгә кертергә:

муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре һәм социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннарны яллаучылар өчен һәм күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән һәм гомуми җыелышта капиталь ремонт өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен 1 нче кушымта нигезендә календарь бүлгәләү белән;

муниципаль торак фондының торак урыныннан файдаланган өчен түләү (наем өчен түләү) күләмен 2 нче кушымта нигезендә;

2. Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының карарларын үз көчен югалткан дип танырга:

1) «2022 елга торак-коммуналь хезмәт күрсәтүләргә тарифларны раслау турында» 2021 елның 20 декабрендәге 615 номерлы карары;

2) «2022 елга торак-коммуналь хезмәт күрсәтүләргә тарифларны раслау турында» 2021 елның 20 декабрендәге 615 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 28 мартындагы 133 номерлы карары.

3. Әлеге карарны «Авыл Утлары» - «Сельские Огни» район газетасында бастырып чыгарырга, Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында (http://muslumovo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

4. Әлеге карар үз көченә 2023 елнын 1 гыйнвареннән керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **И.Ф. Салихзянов**

Мөслим муниципаль районы
Башкарма комитетының
2022 елның «06» декабреннэн
№ 719 карарына
1 нче кушымта

**МУНИЦИПАЛЬ ТОРАК ФОНДЫНЫҢ ТОРАК УРЫННАРЫНА НАЕМ ШАРТНАМӘЛӘРЕ ҺӘМ СОЦИАЛЬ НАЕМ ШАРТНАМӘЛӘРЕ БУЕНЧА ТОРАК УРЫННАРНЫ ЯЛЛАУЧЫЛАР ӨЧЕН ҺӘМ КҮПФАТИРЛЫ ЙОРТ БЕЛӘН ИДАРӘ ИТҮ ЫСУЛЫН САЙЛАУ ТУРЫНДА КАРАР КАБУЛ ИТМӘГӘН ҺӘМ ГОМУМИ ҖЫЕЛЫШТА КАПИТАЛЬ РЕМОНТ ӨЧЕН ТҮЛӘҮ КҮЛӘМЕН БИЛГЕЛӘҮ ТУРЫНДА КАРАР КАБУЛ ИТМӘГӘН ТОРАК УРЫННАР МИЛЕКЧЕЛӘРЕ ӨЧЕН ТОРАК УРЫННЫ КАРАП ТОТУ ҺӘМ РЕМОНТЛАУ ӨЧЕН ТҮЛӘҮ КҮЛӘМЕ**

| № т/б | Түләү атамасы | Хезмәт күрсәтү үлчәү берәмлеге | Хезмәт күрсәтүне үлчәү берәмлеге өчен тариф (сумнарда), НДСны исәпкә алып. **(01.01.2023 елдан 31.12.2023 елга кадәр)** |
|---|---|---|---|
| 1 | Торак фонды белән идарә итү | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв. м | 1,56 |
| 2 | Йорт яны территориясен җыештыру | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв. м | 2,81 |
| 3 | Торак бинага агымдагы ремонт | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв. м | 2,68 |
| 4 | Сууткәргеч-канализация челтәрләренә агымдагы ремонт | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв. м | 1,39 |
| 5 | Газ челтәрләренең фасад челтәрләренә техник хезмәт күрсәтү | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв. м | 0,21 |
| 6 | Йорт эчендәге электр челтәрләрен агымдагы ремонтлау | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв. м | 0,73 |
| 7 | Җилләтү каналларына һәм төтен юлларына техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау | аеңа торак бинаның гомуми мәйданы кв. м | 0,18 |

Мөслим муниципаль районы
Башкарма комитетының
2022 елның «06» декабреннән
№ 719 карарына
2 нче кушымта

## Муниципаль торак фондының торак урыныннан файдаланган өчен (наем өчен түләү) түләү күләме

| № т/б | Хезмәтнең исеме | Үлчәү берәмлеге | Түләү күләме, сум |
|---|---|---|---|
| | | | (01.01.2023 елдан 31.12.2023 елга кадәр) |
| 1. | Наем буенча база ставкасы | аена торак урын гомуми мәйданының 1 кв.м | 6,38 |